КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 7 октябрь г.Казань № 1261

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына үзгәреш кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарлары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесен оештыру турында» 2013 ел, 28 февраль, 136 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 29 апрель, 293 нче; 2014 ел, 24 декабрь, 1020 нче; 2016 ел, 2 март, 128 нче; 2016 ел, 26 декабрь, 987 нче; 2017 ел, 8 сентябрь, 642 нче; 2017 ел, 30 октябрь, 820 нче; 2018 ел, 24 июль, 585 нче; 2019 ел, 22 гыйнвар, 30 нчы; 2019 ел, 29 март, 235 нче; 2019 ел, 19 июль, 606 нчы; 2019 ел, 21 сентябрь, 869 нчы; 2019 ел, 16 декабрь, 1149 нчы; 2020 ел, 2 март, 159 нчы; 2020 ел, 23 октябрь, 949 нчы; 2021 ел, 21 гыйнвар, 17 нче; 2021 ел, 30 сентябрь, 933 нче; 2022 ел, 12 гыйнвар, 6 нчы; 2022 ел, 24 октябрь, 1136 нчы; 2023 ел, 20 февраль, 165 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 2 пункттагы «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Түбәндәгеләр үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2006 – 2008 елларда Татарстан Республикасында административ реформа үткәрү турында республика программасын раслау хакында» 2006 ел, 7 июль, 346 нчы карары;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында 2010 елга кадәр дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр базасында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын күтәрү программасын раслау турында» 2008 ел, 15 декабрь, 888 нче карары;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында 2010 елга кадәр дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр базасында дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең сыйфатын күтәрү программасын раслау турында» 2008 ел, 15 декабрь, 888 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 14 декабрь, 853 нче карары.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин